Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№2 (70)

Ноябрь, 2025 нче ел

Бу санда

Нәтиҗәләр киләчәкне билгели! 2

Укучыларның функциональ грамоталыгын үстерү – заман таләбе 2

30 нчы ноябрь - Әниләр көне 3

Ял сәгатьләрендә 4

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### «ЭКОКАЛЕЙДОСКОП» ЭКОЛОГИЯ БЕРЛӘШМӘСЕ УҢЫШЛАРЫ



25 нче ноябрьдә Казанның «Мәскәү» мәдәни үзәгендә Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы вәкилләре катнашында, «Чиста булачак» яшьләр экологик хәрәкәтенең, 2025 елгы экологик сезонына йомгак ясау буенча республика фестивале узды.

«Мөслим гимназиясенең «Экокалейдоскоп» экология берләшмәсе әгъзалары: Мөхәммәтҗанова Зөһрә, Ильясова Аделина, Галимова Айназ (9 нчы сыйныф), Газетдинова Азалия (11 нче сыйныф) һәм җитәкчеләре Бариева Ләйсән Фәхәметдин кызы «Чиста булачак» республика экология яшьләр хәрәкәтенең Рәхмәт хатлары белән бүләкләнделәр.

«Иң яхшы эконаставник» номинациясендә Бариева Ләйсән Фәхәметдин кызы җиңүче булды. Котлыйбыз! Алга таба да уңышлар телибез!

### ФИРДҮС ГЫЙМАЛТДИНОВНЫҢ “ҮЛЕМНӘН БЕР АДЫМ АЛДАРАК” ӘСӘРЕ БУЕНЧА КИТАП УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ



Мөслим гимназиясендә Фирдүс Гыймалтдиновның “Үлемнән бер адым алдарак” әсәре буенча китап укучылар конференциясе уздырылды.

Чарада Мөслим районының татар теле һәм әдәбияты укытучылары, гимназиянең 9 нчы, 10 нчы сыйныф укучылары катнашты. Педагог- китапханәче Солтанова Г.М. электрон презентация ярдәмендә Ф.Гыймалтдиновның тормыш юлы, иҗаты белән таныштырды. Күргәзмәдәге әсәрләренә күзәтү ясады.

Махсус хәрби операция зонасында “Тимер” батальонының 9 нчы ротасында хезмәт иткән, яу кырыннан “Урал“ мотоциклы белән 126 яралы сугышчыны коткарган “Фаза” кушаматлы Казан егете Илнур Хәертдиновның батырлыгына багышлап язылган әсәр беркемне дә битараф калдырмады.

Укучылар әсәрдән өзекләр сәхнәләштерделәр, геройларга багышлап язылган шигырьләр сөйләделәр, үзләренең күңелләренә тирән үтеп кергән эпизодлар турында фикер алыштылар.

Конференциягә кунак итеп чакылган райондашыбыз - хәрби операция зонасында хезмәт итеп, бүгенге көндә кыска вакытлы ялда булган майор, “Мөслим муниципаль районының мактаулы гражданины” Миргалауов Руслан Габделфаяз улының чыгыш ясавы, укучыларга биргән киңәшләре йөрәкләргә үтеп керерлек булды. Ул тыныч тормышның һәр мизгеленә сөенергә, әти-әниеңне, укытучыларны, туган мәктәбеңне, авылыңны, Ватаныңны яратырга, тырышып укырга кирәклеге турында сөйләде.

## НӘТИҖӘЛӘР КИЛӘЧӘКНЕ БИЛГЕЛИ

Мөслим гимназиясе үзенең ишекләрен 2003 нче елда ача. Гимназиядә һәр яктан камил шәхес тәрбияләүгә зур игътибар бирелә. Чыгарылыш укучылары югары уку йортларына кереп белем алуларын дәвам итәләр. Алар арасында табиблар, педагоглар, фән һәм мәдәният эшлеклеләре бар.

Эш дәверендә гимназия югары күрсәткечләргә иреште. Ел саен укучыларыбыз район, республикакүләм, рәсәйкүләм, халыкара бәйгеләрдә, олимпиадаларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашып, призлы урыннар яулыйлар.

Уку йорты эшчәнлеге бала тормышының аерылгысыз өлеше. Бала гимназиядә вакыт үткәрми, бала гимназиядә яши.

Укучыларның югары балларга БДИ тапшырулары моның нәтиҗәсе булып тора. Ел саен мәктәпне медальга тәмамлаучылар саны да арта бара.

2022 нче елдан башлап ЕГЭ ны 100, 200 баллга тапшыручы укучыларыбыз бар.

2022 нче елда – Баянов Шамил, химия һәм биология фәненнән, 2023 нче елда Исмәгыйлова Лиана, шулай ук биология, химия фәннәреннән, 2024 нче елда Бариева Илина, 2025 нче елда Авзалова Нәргизә - химия фәненнән ЕГЭларны 100 баллга тапшырдылар. Укучыларны әзерләүдә укытучыларның өлеше гаять зур. Укытучыларыбыз һәммәсе дә үз фәненә тугры. Укучыларның уңышлары нигезендә, педагогның тынгысыз хезмәте ята.

2023 нче елны медицина сыйныфлары ачылу да зур сөенеч булды, бу сыйныфларда укучы егет-кызлар Казан дәүләт медицина университеты һәм Әлмәт медицина көллияте укытучылары үткәргән дәресләрне көтеп алалар.

Безнең гимназиянең миссиясе - укучыларның мөмкинлекләрен, белем алуга омтылышларын исәпкә алып, үсеш өчен шартлар тудыру. Мәктәп укучылары алган белем бүген һәм киләчәктә аларның тормышта үз юлларын табуда ярдәм итәргә тиеш.

Соңгы биш елда укучыларның гимназияне уңышлы гына тәмамлап югары уку йортларына, техникум, колледжларның түләүсез бүлекләренә уңышлы гына керүләре, үсеш күзәтелә. Аеруча медицина, юридик, психология, техник юнәлеш сайлаучы укучыларыбыз күп.

***Лира Заялова,***
***гимназиянең уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары***



**2025 нче ел –**

***Нәргизә Авзалова***

***Химия - 100***

***Казан дәүләт медицина университеты студенты***

## УКУЧЫЛАРНЫҢ ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫГЫН ҮСТЕРҮ – ЗАМАН ТАЛӘБЕ

***Нәрсә соң ул “функциональ грамоталылык”?***

**Функциональ грамоталылык** – кешенең тышкы мохит белән мөнәсәбәтләргә керү, тиз җайлашу һәм анда эшләү сәләте. Функциональ грамоталылык нигезләре башлангыч мәктәптә салына, анда сөйләм эшчәнлегенең төрле төрләренә – язуга, укуга, сөйләшүгә һәм тыңлауга интенсив өйрәтү бара.

Функциональ яктан белемле шәхес - ул:

– дөньяда ориентлашкан һәм иҗтимагый кыйммәтләргә, өметләр һәм мәнфәгатьләргә туры китереп эшли торган, аерым алганда, үз гамәлләрен башка кешеләрнең гамәлләре белән яраштыра һәм координацияли белүче кеше;

– сайлау һәм карарлар кабул итү ситуациясендә мөстәкыйль булырга сәләтле кеше;

– үз карарлары өчен җавап бирә белүче кеше;

– үз-үзең һәм якыннарың өчен җаваплы булырга сәләтле кеше;

- төрле алымнарга ия һәм үз өстендә даими эшләргә әзер кеше;

– төрле белем өлкәләрендәге компетенцияләргә ия булган шәхес;

- аның өчен стандарт булмаган ситуациядә чишү юлларын эзләү-гадәти күренеш;

– кешеләр арасында аралашу чарасы буларак тел һәм язма сөйләмне яхшы белүче;

- заманча мәгълүмати технологияләргә ия булган кеше.

**Алымнар:**

- Проект эшчәнлеге технологиясе.
- Проблемалы ситуацияне тәзү нигезендә критик фикерләү технологиясе: деформацияләнгән текст өстендә эшләү.
- Мәгълүмати һәм коммуникатив технологияләр (интернет, мульти-медиа чаралары, китапханә).

**Функциональ белемле шәхес нинди осталыкларга ия булырга тиеш?**

1. Сөйләм осталыгы:
- яңа материалны үзләштерү,
- дәреслек, сүзлек белән эш итә белү,
- танып белү активлыгын үстерү,

2. Интеллектуаль-сөйләм осталыгы:
- Рецептив (тыңлый һәм укый белү);
- Укуның төрле төрләрен куллану;
- Текстны структур-мәгънәви өлешләргә бүлү;
- Текстка мөстәкыйль рәвештә сораулар куя белү;
- Текст авторы белән диалог алып бару;
- Укытучының текст буенча биргән сорауларына җавап бирү;
- Текста төп фикерне билгеләү;
- Текст планын төзи белү;
- Төп сүзләрне таба белү;
- Текст исемен аның эчтәлеге белән тәнгәл китерү;
- Планга таянып текстның эчтәлеген тулысынча сөйләү;



- Текстка исем бирү;

3. Коммуникатив осталык:
– укытучы һәм яшьтәшләре белән диалогка керү;
- үз сүзенне әйтә һәм дәлилли белү;
– проблеманы (сорау, бирем) төркемдә (парда) хәл итү;

Бүгенге укучыларга үсешенең уңышлы траекториясен төзү өчен нинди һөнәри һәм гамәли күнекмәләр кирәк булачагын без фаразлый алмыйбыз. Әмма тотрыксызлык, киләчәктә аларның үз позициясен ныгыту өчен, без, укытучылар, һичшиксез, укучыларны функциональ грамоталылыкка өйрәтергә тиеш.

***Лилиана Миңнегалиева,***
***гимназиянең методик эшләр буенча директор урынбасары***

# 30 НЧЫ НОЯБРЬ – ӘНИЛӘР КӨНЕ

*Ноябрьнең соңгы якшәмбесендә Россиядә Әниләр көне бәйрәм ителә. Әни - безне үз йөрәк астында йөртеп, якты дөньяга аваз салган көннән башлап кайгыртучы, олы тормышка аяк баскач, үзенең киңәшләрен бирүче, безнең өчен һәрвакыт догада булучы иң якын һәм изге кеше.*

*Без нинди генә дәрәҗәле урыннарда эшләсәк тә, нинди генә җиңүләргә ирешсәк тә, әниләребезгә рәхмәтле булырга тиешбез. Татар халкында "Җәннәт - әниләрнең аяк астында" дигән бик матур бер мәкаль бар. Шуңа күрә сөекле әнкәйләргә карата, әни исемен горур йөртүче хатын-кызларга карата хөрмәт һәм мәрхәмәт күрсәтик. Олы бүләкләребезне, җылы сүзләребезне кызганмыйк.*

*Өйләребез һәрвакыт әнкәйләребезнең якты елмаюлары белән ямьләнеп торсын. Әниләр исән булганда, ничә яшьтә булуга карамастан, без бала булып калабыз. Дөньядагы барлык әниләргә дә сәламәтлек һәм бәхетле озын гомер телибез.*

*Гимназиядә дә әниләр көненә багышланган чаралар үтә.*









***Мөслим гимназиясенең 6 нчы б сыйныфы укучыларының әниләренә карата булган изге теләкләре***



**Минем әнием**

Минем әнием Фирүзә исемле. Минем әнием дөньяда минем өчен бик кадерле кеше. Ул безне - апаем белән мине бик нык ярата.

Әнием безгә тәмле ризыклар пешерә, сыйлап кына тора. Мин үзем дә әниемнең кечкенә булышчысы, өй җыештырам, савыт-саба юам. Тиздән әниләр көне җитә. Әниләр көне матур, җылылык бөркелеп торган бәйрәмнәрнең берсе. Аңа үземнең рәхмәтләремне җиткерәсем килә. Без сине бик нык яратабыз, әнием! Бәхет, шатлык телим, беркайчанда авырма!

***Бариева Ралина***

***

Минем әнинең исеме Лилия. Ул - бик кадерле кешем.

Әнием безгә тәмле әйберләр пешерә. Мин дә аңа булышам.

Без гаиләдә биш бала: өч апам һәм бер апаем бар. Бишебезне карау, тәрбияләү өчен күпме көч кирәк!

Тиздән әниләр бәйрәме җитә. Мин әниемне бәйрәм белән котлыячакмын.

Әнием, сиңа сәламәтлек, бәхет-шатлык телим. Мин сине бик-бик нык яратам.

***Сабитов Сәмир***

***

Табигатьтә нинди һава торышы булуга да кармастан, һәр иртә бүлмәбездә кояш нурлары балкый. Ни өчен? Чөнки өебездә кояшыбыз - әниебез бар. Һәр иртәне "әни" дип әйткәч, көн тагын да матурланган кебек тоела.

Минем әнием Гөлназ исемле. Без гаиләдә бишәү. Мин һәм абыйларым әнине бик яратабыз. Безгә әни гел ярдәм итә. Ул - өебез патшабикәсе. Өйне җыештыра, ашарга пешерә. Күп вакытта әниемә миндә ярдәм итәм. Иртән мәктәпкә киткәндә, әнием: "Әйбәт укуыңны телим!" диеп озатып кала. Кайткач: "Көнең ничек үтте, балам?" диеп сорый.

"Әни" сүзе бик зур мәгънәгә ия. "Әни" дип дәшкәч, күңелгә җылылык йөгерә. Безгә әниебез бик кадерле! Аңа озын гомер, сәламәтлек, шатланып яшәвен телим.

***Гиздуллин Рүзәл***

***

Әни... Бу өч хәрефле сүз үз эченә бик күп мәгънә сыйдырган.

Әнием Лилия исемле. Ул бик уңган безнең! Пешерә дә, җыештыра да, өй эшен дә эшләтә һәм эшкә дә йөри. Һәркөнне, эштән никадәр арып катса да, тәмле итеп ашарга пешереп безне сыйларга да, мәктәп хәлләрен, укуыбызны сорашырга да өлгерә.

Без әниебезгә өчәү: апам, апаем һәм мин. Ул һәрберебез өчен дә борчыла, безнең кечкенә уңышларыбызга да сөенә. Бик тә яратам мин әниемне. Аңа чиксез бәхет, сәламәтлек телим.

***Биккинина Камилә***

***

Минем әниемнең исеме - Руфия. Мин аны бик нык яратам! Һәр көнне иртән торганда өйгә тәмле ис тарала. Бу - әниемнең эше. Ул иртәнге чәйгә тәмле әйбер пешереп куйган була.

Әни пироглар пешерергә, гөлләр үстерергә ярата. Мин дә мәктәптән кайткач аңа өй эшләрендә булышам.

Әни сүзе бик кадерле сүз. Әниләр безне тудыручылар, үстерүчеләр, дөрес тәрбия бирүчеләр, тормышта үз юлыбызны табарга булышучылар. Шуңа күрә, әниләргә рәхмәт әйтеп кенә торырга кирәк. Әниемә мине үстергән, төпле киңәшләр биргәне өчен рәхмәт әйтәсем килә. Сәламәт бул, мин сине бик нык яратам, газиз кешем!

***Латыйпова Иркә***

***

Минем әнием Динара исемле. Ул миңа бик кадерле! Мин аны гаҗәеп дәрәҗәдәге яхшылыгы өчен яратам.

Әнием бик матур да минем. Аның күзләре дә матур, чәчләре дә искиткеч хуш исле, куллары да җылы һәм назлы. Авырган чагымда ул кулларын минем маңгайга кую белән, бөтен авыруым бетә.

Без - әнигә дүрт бала. Минем абыем, ике апаем бар, без барыбыз да малайлар.

Кызлары булмагач, без аңа өй эшләрендә дә булышырга тырышабыз.

Бәләкәй апаем белән өйдә торса да, әни "Фармаси" компаниясендә эшләргә, кешеләргә матурлык өләшергә дә өлгерә.

Рәхмәт, әнием, барысы өчен дә зур рәхмәт!

***Сәетгалиев Данияр***

## ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

### ГЕРОЙ-ШӘҺӘРЛӘРНЕ БИЛГЕЛӘ

| | | | |
|---|---|---|---|
| Казан | Вологда | Севастополь | Новороссийск |
| Мәскәү | Волгоград | Тула | Санкт-Петербург |
| Омск | Брест | Курск | Краснодар |
| Сочи | Минск | Смоленск | Уфа |
| Керчь | Самара | Мурманск | Воронеж |




Филворд Филворд Филворд

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| К | А | Һ | К | И | Р | М | Ә | Н | Й |
| Ц | Щ | А | А | Й | А | Ц | Ж | А | Ц |
| Й | А | Р | М | Ә | С | К | Ә | Ү | Щ |
| Г | Ц | М | А | Н | Ж | Щ | С | Ж | Ж |
| О | Й | Й | Л | Щ | Б | Ц | И | Й | Ц |
| С | М | Ж | Ы | Й | А | Й | Р | А | К |
| П | Е | Д | Ш | Ж | Ц | Ж | Л | А | А |
| И | А | А | Ц | Щ | Й | Ц | Е | Д | А |
| Т | А | Л | Ь | Ж | Ц | Й | К | О | Й |
| Щ | Ж | Й | Щ | Ж | Й | Ц | Ж | Г | А |

***Түбәндәге сүзләрне эзләп тап:***

1. Кирмән
2. Ладога
3. Камалыш
4. Байрак
5. Медаль
6. Каһарман
7. Мәскәү
8. Әсирлек
9. Госпиталь

***КАДЕРЛЕ ГАЗЕТА УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!***

Җавапларыгызны түбәндәге электрон адреска *tilsim2014@yandex.ru юллагыз.*

ТЫЛСЫМ+
Ноябрь, 2025 нче ел
№2 (70)
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.

**Мөхәррир:** Замалова Зәринә
**Корректорлар:** Хәйруллина Диләрә
**Корреспондентлар:** Насырова Мәрьям, Фәхрәзиева Алинә
**Дизайнер:** Мостафина Рәйлә
**Компьютерда җыючылар:** Вагыйзов Айзат, Сәләмов Наил

*2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә*

**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim2014@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3)
**Тираж:** 100